

Ботен Россия бәйрәм иткән кvк, Мордовия моселменнары да унынчы апрельдә изге Ураза Гаетен бәйрәм итәбез.
Хормәтле моселманнарыбыз! Кадерле якташларыбыз!
Сезне Ураза бәйрәме белән ихлас кvнелдән котлыйбыз! Һәрбер моселман очен зур сынау булган ураза вакытын – Рамазан аен тогәлләvче бу мокатдәс бәйрәм жир йозенә игелек һәм шәфкать кебек гомумкешелек кыйммәтләрен тарата, эчке доньябызны камилләштерергә момкинлек бирә.
Рамазан аенда без уй-ниятләребезне Аллаһнын мәрхәмәтен яулауга, бер-беребезгә рәхим-шәфкать кvрсәтvгә һәм игелек кылуга юнәлттек. Якыннарыбыз турында кайгыртып, мохтажларга ярдәм итеп, мәхәббәт, игелек һәм кин кvнеллелек чагылышы булган әлеге кvркәм омтылышларны йорәгебез тvрендә һәрчак саклыйк.
Ураза гаетендә Аллаһы Тәгалә кvнелләребезгә иман һәм мәрхәмәтлек нуры остәсен, һәркайсыбызга жан тынычлыгы, шатлык һәм бәрәкәт бvләк итсен. Олуг бу бәйрәм һәммәбезгә рухи янарыш шатлыгы, хезмәт дәрте бирсен, бердәмлеккә рухландырсын! Сезгә бәхет, исәнлек-саулык, тынычлык һәм иминлек телибез!